Национальная
библиотека
Республики Татарстан

# Сәфәр чыгар аты бар...

Күренекле татар язучысы
Ринат Мөхәммәдиевнең
75 яшьлек юбилеена багышланган
методик-библиографик ярдәмлек

Казан
«Милли китап» нәшрияты
2023

# Сәфәр чыгар аты бар...

Күренекле татар язучысы
Ринат Мөхәммәдиевнең
75 яшьлек юбилеена багышланган
методик-библиографик ярдәмлек

Казан
«Милли китап» нәшрияты
2023

**УДК 025.5**
**ББК 78.37**
**С 96**

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең
редакция-нәшрият шурасы карары белән басыла

*Төзүчесе З.Ә.Җамалиева*
*Мөхәррире И.Г.Һадиев*


**С 96** Сәфәр чыгар аты бар...: күренекле татар язучысы Ринат Мөхәммәдиевнең 75 яшьлек юбилеена багышланган методик-библиографик ярдәмлек /Татарстан Респ. Милли к-ханәсе; төз. З.Ә.Җамалиева; мөх-ре И.Г.Һадиев. – Казан: Милли китап, 2023. – 40 б.

Ярдәмлек Ринат Мөхәммәдиевнең тормыш юлына һәм иҗатына багышланган әдәбият белән эшләү өчен китапханәчеләргә тәкъдим ителә. Бирелгән материалларны семинарлар, әдәби кичәләр, фикер алышулар һәм башка мәдәни чаралар үткәрүдә файдаланып була.

**УДК 025.5**
**ББК 78.37**

© Татарстан Республикасы
Милли китапханәсе, 2023;
© «Милли китап» нәшрияты, 2023.

# КЕРЕШ СҮЗ



Язучы, әдәбият галиме һәм җәмәгать эшлеклесе Ринат Сафа улы Мөхәммәдиев 1948 елның 10 декабрендә Татарстанның Мамадыш районы Кече Кирмән авылында игенче гаиләсендә туа. Ринат 1966 елда шул төбәкнең Түбән Ушмы унберьеллык мәктәбен, 1971 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый, аннан өч ел дәвамында Казан телевидение студиясендә яшьләр-балалар тапшырулары мөхәррире булып эшли. 1973–1976 елларда Казан дәүләт университетының журналистика кафедрасы каршындагы аспирантурада укый.

Аспирантураны тәмамлап, берникадәр вакыт «Татарстан коммунисты» (хәзерге «Татарстан») журналы идарәсендә фән һәм мәдәният бүлегенә җитәкчелек итә, аннары 1977 елның февраленнән «Казан утлары» журналы редакциясендә әүвәл әдәби тәнкыйть бүлеге мөхәррире, аннары 1981 елның маеннан 1987 елның көзенә кадәр журналның баш мөхәррир урынбасары булып эшли. 1987–1989 елларда ул – Татарстан китап нәшрияты директоры хезмәтендә. 1979 елда Ринат Мөхәммәдиев Мәскәү университеты каршындагы гыйльми советта «Татар әдәби тәнкыйтенең формалашу проблемалары» дигән темага диссертация яклап, филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә ала.

Әдәби иҗат эше белән Ринат Мөхәммәдиев мәктәптә укыган елларында ук кызыксына башлый: шигырьләр, хикәяләр яза. Аның ул вакыттагы беренче иҗат тәҗрибәләреннән кайбер үрнәкләр көндәлек матбугат битләрендә, республика балалар газетасы «Яшь ленинчы»да (хәзерге «Сабантуй» журналы) басылып чыга. Аспирантурада уку елларыннан

башлап исә ул, нигездә, төп игътибарын әдәби тәнкыйть өлкәсенә юнәлтә һәм чагыштырмача кыска вакыт эчендә республика матбугатында бер-бер артлы җитди, тирән эчтәлекле тарихи-әдәби һәм рецензия характерындагы мәкаләләрен бастыра.

Аның беренче татар профессиональ театр тәнкыйтьчесе Габдрахман Кәрамнең, күренекле тел һәм әдәбият галиме Җамал Вәлидинең тормыш һәм иҗат эшчәнлекләре, үзләреннән соң калдырган әдәби мираслары хакында тирән өйрәнеп һәм кайгыртып язган, ул заман өчен шактый кыю фикерле, принципиаль карашлы мәкаләләре әдәби җәмәгатьчелектә зур кызыксыну уяталар. Үткәндәге тәнкыйди әдәби мирасны өйрәнү белән бергә, яшь галим агымдагы әдәби хәрәкәтне дә күзәтеп бара һәм Х.Туфан, С.Хәким, Н.Арсланов, Ш.Галиев, И.Юзеев, Р.Фәйзуллин, Г.Рәхим кебек үзенчәлекле шагыйрьләрнең, Ә.Еники, А.Расих, А.Гыйләҗев, М.Мәһдиев кебек күренекле прозаикларның, драматург Т.Миннуллинның иҗат портретларын, татар әдәбиятының шул еллардагы гомуми хәле, үсеш тенденцияләре, табышлары һәм югалтулары хакында җитди итеп, фәнни нигездә анализлап язган проблемалы мәкаләләрен бастыра. Галим-тәнкыйтьченең бу төр фәнни тикшеренүләре һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре аның «Әгәр без янмасак…» (1980), «Проблемы формирования татарской литературной критики» (1982), «Якутлар табыладыр вакыт белән» (1983) исемле китапларында урын ала.

Узган гасырның җитмешенче еллары ахырларында Ринат Мөхәммәдиев, тәнкыйди иҗат эшчәнлеген дәвам итеп, әдәбиятның проза жанрында да каләмен чарларга керешә. 1979 елда аның нәниләр өчен «Яңа елга күчтәнәч» исемле зур булмаган беренче хикәяләр җыентыгы басылып чыга, ә берникадәр вакыттан соң татар авылы тормышын, нигездә, яшь буын кешеләре һәм өлкәннәр ара-



сындагы үзара мөнәсәбәтләрне, мәхәббәт коллизияләрен һәм кичерешләрен әхлакый яссылыкта тасвирлаган «Беренче умырзая» (1983), «Ак кыялар турында хыял» (1985), «Истәлек өчен Гыйлемханга» (1986) исемле лирик повестьлары һәм бер төркем хикәяләре иҗат ителәә.

1989 елда исә ул үзенең беренче күләмле әсәрен – «Кенәри – читлек кошы» исемле романын язып тәмамлый. Торгынлык чоры совет җәмгыятенең, бигрәк тә аның түрәлек итүче катлавының әхлаксызлык сазлыгына бата баруын, деградациясен, араларында хөкем сөргән гаделсезлек, ришвәтчелек, азгынлык, эчкечелек, фахишәлек кебек яман гадәтләрен әдәби чаралар, тормышчан, маҗаралы-драматик вакыйгалар һәм гомумиләштерелгән кеше типлары, каһарманнары аша чынбарлыкны калку итеп гәүдәләндергән бу романы белән Ринат Мөхәммәдиев 1990 нчы еллардагы татар прозасының үзенчәлекле тәнкыйди бер юнәлешен башлап җибәрә. Укучылар тарафыннан гаять җылы кабул ителгән бу әсәр кыска гына вакыт эчендә




татар һәм рус телләрендә ике мәртәбә зур тиражлар белән басылып чыга.

Әдәби иҗаттагы уңышлары белән бергә, бу елларда Ринат Мөхәммәдиев актив җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе буларак та киң танылa. 1989 һәм 1995 елларда каләмдәшләре аны ике мәртәбә Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең рәисе итеп сайлыйлар. Ул ун ел дәвамында, ягъни 1999 елның июленә кадәр Язучылар берлеге белән җитәкчелек итә. Бер үк вакытта 1990–1993 елларда, Татарстаннан Россия Югары Советына сайланган халык депутаты буларак, Россия Югары Советының Президиумы әгъзасы һәм Югары Советның Мәдәният һәм милли мәсьәләләр буенча даими комиссиясе рәисе булып эшли. 1995–2000 елларда ул шулай ук Татарстан Республикасы халык депутаты вазифаларын башкара.

Мәскәүдә эшләү дәверендә (1990–1993), депутатлык вазифаларын үтәп бару белән бергә, Ринат Мөхәммәдиев татарның мәшһүр тарихи шәхесе, күренекле сәясәтче, дәүләт эшлеклесе, колониаль изү астында яшәгән төрки һ.б. халыкларның милли азатлыгы хәрәкәте теоретигы Мирсәет Солтангалиевнең тормышы һәм иҗтимагый

эшчәнлеге турында үзәк архивларда сакланган, моңарчы киң җәмәгатьчелеккә мәгълүм булмаган документларны җентекләп өйрәнә. Шул тарихи документлар һәм әдипнең иҗат фантазиясе нигезендә күренекле милләттәшебезнең каһарман образын калку итеп тасвирлаган «Сират күпере» романы туа.

Роман җәмәгатьчелек тарафыннан хуплап каршы алына, матбугатта әдипнең чираттагы иҗади уңышы дип бәяләнә. 1993 елда «Сират күпере» романы өчен Ринат Мөхәммәдиев Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. Әсәр тиз арада рус, француз, төрек, македон, кытай телләренә тәрҗемә ителә, төрекчә басмасы (Истанбул, 1993) Төркиянең халыкара әдәби бүләгенә лаек була (1995). Төрек телендә



бу роман кабат-кабат басылып чыга. «Сират күпере» романы шулай ук Евразия һәм Африка илләренең мәртәбәле «Лотос» бүләге (1998) һәм А.Платонов исемендәге премия (1995) белән тамгалана.

Ринат Мөхәммәдиевнең туксанынчы елларда иҗат иткән һәм халыкара яңгыраш тапкан әдәби әсәрләреннән тагын берсе – «Утлы таба өстендә» исемле документаль повесть (1995). Анда авторның үз күз алдында узып, үз башыннан кичергән тарихи вакыйгалар – СССРның җимерелү тарихы, 1991 елның август, 1993 елның сентябрь-октябрь айларында Россия парламенты белән Президент Б.Н.Ельцин һәм аның ярдәмче аппараты арасында хакимият өчен барган сәяси көрәш һәм канлы бәрелеш вакыйгалары бәян ителә, әдип тарафыннан бу гауга-талашларда катнашучы реаль шәхесләрнең кылган эшгамәлләренә, фигыль-холыкларына бәя бирелә.

Әсәр рус телендә һәм тагын берничә илдә басылып чыга. Повестьның «Крушение» дигән исем астында чыккан тулыландырылган икенче русча басмасы өчен Р.Мөхәммәдиев 2002 елда М.Шолохов исемендәге Халыкара премиягә лаек дип табыла.

Ринат Мөхәммәдиев – Татарстанның (1986) һәм Россия Федерациясенең (2010) атказанган мәдәният хезмәткәре, Россия Гуманитар фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы (1997), Россия Табигать фәннәре академиясе академигы (2021),

Ул хәзерге көндә Мәскәүдә Халыкара Язучылар берлегенең рәис урынбасары булып эшли, Мәскәүдә чыга торган «Татарский мир» («Татар дөньясы») дигән иҗтимагый-сәяси газетаның баш мөхәррире вазифаларын башкара. Ул шулай ук – Халыкара Язучылар берлеге әгъзасы.

Ринат Мөхәммәдиев – 1979 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.

Ринат Мөхәммәдиев исеме укучыларга яхшы та-

ныш. Юбилей уңаеннан китапханәләрдә төрле чаралар: конференцияләр, китап күргәзмәләре, әдәби кичәләр һәм очрашулар, китапларга күзәтү, әдәби әңгәмәләр һәм лекцияләр, викториналар үткәрергә киңәш итәбез. Ринат Мөхәммәдиевнең тормышы һәм иҗатына багышланган кайбер мәгълүматларны һәм фоторәсемнәрне Интернет челтәреннән, әдипнең рус һәм татар телләрендәге Шәхси сайтыннан да алырга, шулай ук Интернет челтәрендә әсәрләрен укырга да мөмкин.

**Ринат Мөхәммәдиев әсәрләре Интернет челтәрендә:**
**Татар телендә:**
http://rinatmuhamadiev.ru/ay_bylbylym.html Ай былбылым... (Хикәя)
http://rinatmuhamadiev.ru/bel_skal_t_0.html Ак кыялар турында хыял (Повесть)
http://rinatmuhamadiev.ru/alabay.html Алабай (Хикәя)
http://rinatmuhamadiev.ru/ach_ter.html Ачык тәрәзә (Хикәя)
http://rinatmuhamadiev.ru/bar_tik.html Бары тик беренче (Хикәя)
http://rinatmuhamadiev.ru/bez_en.html Безнең әниләр бәхете (Хикәя)
http://rinatmuhamadiev.ru/bojak.html Бөҗәк (Хикәя)
http://rinatmuhamadiev.ru/ekber.html Әкбар бабай (Хикәя)
http://rinatmuhamadiev.ru/jawap.html Җавап эзлим (Хикәя)
http://rinatmuhamadiev.ru/istel.html Истәлек өчен – Гыйлемханга (Повесть)
http://rinatmuhamadiev.ru/allany-kashka-t-k-se.html Алланың кашка тәкәсе (Роман)
http://rinatmuhamadiev.ru/ak-kegaz-niden-caragaya.html Ак кәгазь нидән саргая... (Роман)
http://rinatmuhamadiev.ru/karak.html Карак (Хикәя)
http://rinatmuhamadiev.ru/kireb.html Киребеткән кыз (Хикәя)
http://rinatmuhamadiev.ru/kosh_bul.html Кош булып очар идем... (Роман)
http://rinatmuhamadiev.ru/kynel.html Күңел күзе (Хикәя)
http://rinatmuhamadiev.ru/kargay.html Кыргый атауга сәяхәт (Хикәя)
http://rinatmuhamadiev.ru/madam_tat.html Мадам Анет (Хикәя)
http://rinatmuhamadiev.ru/muen.html Муенсалы Күгәрчен (Хикәя)
http://rinatmuhamadiev.ru/madj.html Мәҗит абыйдан сәлам... (Хикәя)
http://rinatmuhamadiev.ru/pran.html Перәникле төшләрем... (Хикәя)

http://rinatmuhamadiev.ru/sani_tat.html Сания (Хикәя)
http://rinatmuhamadiev.ru/ayazuchan-bolytly-ava.html Аязучан болытлы һава...(Хикәя)
http://rinatmuhamadiev.ru/kenery-chitlek-koshi.html Кенәри – читлек кошы (Роман)
http://rinatmuhamadiev.ru/sirat.html Сират күпере (Роман)
http://rinatmuhamadiev.ru/tat_bahet.html Татарча бәхет (Хикәя)
http://rinatmuhamadiev.ru/tugan.html Туган якка кайтышлый (Хикәя)
http://rinatmuhamadiev.ru/urman.html Урман карачкысы (Хикәя)
http://rinatmuhamadiev.ru/yz_keshe.html Үз кешеләр (Хикәя)
http://rinatmuhamadiev.ru/fatim_apa.html Фатыйма апа (Хикәя)
http://rinatmuhamadiev.ru/farshta_kanat.html Фәрештә канаты (Хикәя)
http://rinatmuhamadiev.ru/chijalangan.html Чияләнгән төен (Хикәя)
http://rinatmuhamadiev.ru/shamil.html Шамил абый (Хикәя)
http://rinatmuhamadiev.ru/berenche_umirzaya.html Беренче умырзая (Повесть)
http://rinatmuhamadiev.ru/k-zachkysyz-buran.html Күзачкысыз буран...(Роман)

**Рус телендә:**
http://rinatmuhamadiev.ru/bel_skal_0.html Белые скалы
http://rinatmuhamadiev.ru/vzlet_0.html Взлететь бы мне птицей...
http://rinatmuhamadiev.ru/glaza_d.html Глаза души
http://rinatmuhamadiev.ru/gol_o.html Голубка с ожерельем
http://rinatmuhamadiev.ru/ded_ak.html Дедушка Акбар
http://rinatmuhamadiev.ru/zhuk.html Жук
http://rinatmuhamadiev.ru/kapriz.html Капризуля

http://rinatmuhamadiev.ru/krusheniye_0.html Крушение
http://rinatmuhamadiev.ru/kr_ang.html Крылья ангела
http://rinatmuhamadiev.ru/peremennaya-oblachnost.html Переменная облачность...
http://rinatmuhamadiev.ru/les_pug.html Лесное пугало
http://rinatmuhamadiev.ru/madam.html Мадам Анет
http://rinatmuhamadiev.ru/marsh.html Марш жуликов
http://rinatmuhamadiev.ru/most.html Мост над адом
http://rinatmuhamadiev.ru/Nalich.html Наличники
http://rinatmuhamadiev.ru/otkr_okno.html Открытое окно
http://rinatmuhamadiev.ru/pryan.html Пряничные сны
http://rinatmuhamadiev.ru/put_ost.html Путешествие на дикий остров
http://rinatmuhamadiev.ru/ran_ves.html Ранняя осень в деревне
http://rinatmuhamadiev.ru/sani.html Сания
http://rinatmuhamadiev.ru/svoi.html Свои люди
http://rinatmuhamadiev.ru/solovey.html Соловей мой
http://rinatmuhamadiev.ru/shv_bar.html Схватка на бархане
http://rinatmuhamadiev.ru/sch_mat.html Счастье наших матерей
http://rinatmuhamadiev.ru/teni_0.html Тени в сумерках
http://rinatmuhamadiev.ru/tish.html Тишина
http://rinatmuhamadiev.ru/tolko_perv.html Только первым
http://rinatmuhamadiev.ru/udr_bal.html Удравший балеш

## ӘҢГӘМӘЛӘР ҮТКӘРҮ ӨЧЕН ЯКЫНЧА ТЕМАЛАР:

– Язучының тәрҗемәи хәле белән таныштыру, аның язучы буларак төрле жанрларда иҗат итүен яктырту:

– Ринат Мөхәммәдиев – әдәбият галиме;

– Ринат Мөхәммәдиев – язучы;

– Ринат Мөхәммәдиев – журналист;

– Мәдәният, фән һәм әдәбият әһелләренең Ринат Мөхәммәдиев турындагы фикерләрен белдерү һ.б. темалар.

**Файдалану өчен әдәбият исемлеге**

**Китаплары:**


1. Мөхәммәдиев Р. Ак канатлы кояш: повесть. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 22 б.
2. Мөхәммәдиев Р. Ак кәгазь нидән саргая: әдәби-документаль романнар. – М.: Голос-Пресс, 2023. – 397 б.
3. Мөхәммәдиев Р. Ак кыялар турында хыял: повесть, хикәяләр. – Казан: Мәгариф, 1995. – 240 б.
4. Мөхәммәдиев Р. Алланың кашка тәкәсе: роман. – М.: Советский писатель, 2002. – 236 б.
5. Мөхәммәдиев Р. Ат чабышы: хикәя. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – 20 б.
6. Мөхәммәдиев Р. Әгәр без янмасак…: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – 144 б.
7. Мөхәммәдиев Р. Беренче умырзая: повестьлар, хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – 208 б.
8. Мөхәммәдиев Р. Кайларда сез, авылдашлар... – Казан: Татар. кит. нәшр., 2022. – 443 б.
9. Мөхәммәдиев Р. Канатлы кояш = Солнышко белокрылое: хикәя. – Казан: Мәгариф, 1998. – 39 б.
10. Мөхәммәдиев Р. Кенәри – читлек кошы: роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 448 б.
11. Мөхәммәдиев Р. Кош булып очар идем...: роман. – М.: Голос-Пресс, 2007. – 237 б.

12. Мөхәммәдиев Р. Күзачкысыз буран: роман. – М.: Голос-Пресс, 2016. – 289 б.

13. Мөхәммәдиев Р. Кыргый атауга сәяхәт. – Казан: «Казан утлары» журналы редакциясе, 2022. – 158 б.

14. Мөхәммәдиев Р. Сират күпере: роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – 528 б.

15. Мөхәммәдиев Р. Утлы таба өстендә: баштан кичкән фаҗига. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. – 223 б.

16. Мөхәммәдиев Р. Үз кешеләр; хикәяләр, повестьлар. – Москва: Голос-Пресс, 2011. – 463 б.

17. Мөхәммәдиев Р. Чияләнгән төен: повесть, хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. – 208 б.

18. Мөхәммәдиев Р. Юлда булу хәерле: хикәяләр, повестьлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. – 589 б.

19. Мөхәммәдиев Р. Якутлар табыладыр вакыт белән: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. – 216 б.

20. Мөхәммәдиев Р. Яңа елга күчтәнәч: хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. – 32 б.

**Рус телендәге китаплары:**

1. Мухамадиев Р. Крушение: хроника бешеных дней. – Москва: Советский писатель, 2003. – 247 с.

2. Мухамадиев Р. Львы и канарейки, или невинные забавы мафии...: роман / пер. с тат. И. Каримова. – Москва: Современник, 1992. – 303 с.

3. Мухамадиев Р. Мост над адом: роман / пер. с татар. А. Хакимова. – Москва: Голос, 1996. – 479 с.

4. Мухамадиев Р. На раскаленной сковороде: документальная повесть / пер. с татар. – М.: Голос, 1997. – 288 с.

5. Мухамадиев Р. Первый подснежник: повести и рассказы: перевод с татарского. – Москва: Советская Россия, 1990. – 320 с.

6. Мухамадиев Р. Проблемы формирования татарской

литературной критики (1905–1917). – Казань: Татар. кн. изд-во, 1982. – 144 с.

7. Мухамадиев Р. Ранняя осень в деревне: роман, повести, рассказы / пер. с татар. – М.: Советский писатель, 1993. – 462 с.

8. Мухамадиев Р. Свои люди: избранное / пер. с татар.: Р. Фаткуллина [и др.]. – Москва: Дружба литератур, 2012. – 639 с.

9. Мухамадиев Р. Тени в сумерках: роман: пер. с татар. – М.: Голос-Пресс, 2008. – 237с.

**Мәкаләләре:**

1. Мөстәкыйльлек яхшы нәрсә, әлбәттә...: Татарстан язучыларының XII корылтаенда берлек идарәсе Ринат Мөхәммәдиев чыгышыннан // Ватаным Татарстан. – 1994. – 8 июнь.

2. Мөхәммәдиев Р. «Минем тормыш контраст душ»: [язучы Ринат Мөхәммәдиев б-н әңгәмә] / әңгәмәдәш Г. Җәлилова // Шәһри Казан. – 2013. – 4 апрель (№ 39). – Б. 7, 12.

3. Мөхәммәдиев Р. «Хыялның вакытында чынга ашуы кадерле...»: [язучы б-н әңгәмә: аңар 50 яшь] / Әңгәмәдәш Н.Шәйдуллина // Татарстан. – 1998. – № 11–12. – Б. 68–70.

4. Мөхәммәдиев Р. «Эзем калырга тиеш»: [язучы Р.Мөхәммәдиев белән әңгәмә] / әңгәмәдәш Р.Мөхәмметова // Сабантуй. – 1998. – 12 дек.

5. Мөхәммәдиев Р. Безгә бергә булу хәерле...: [Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ринат Мөхәммәдиев б-н әңгәмә] / әңгәмәдәш Салисә Гәрәева // Татарстан хәб. – 1994. – 18 ноябрь.

6. Мөхәммәдиев Р. Безнең әниләр бәхете: [авторга 50 яшь] // Сөембикә. – 1998. – № 12. – Б. 26–28.

7. Мөхәммәдиев Р. Бу дөньяда язучылар күп булганга сөенергә кирәк...: [Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе б-н әңгәмә] / әңгәмәдәш Салисә Гәрәева // Татарстан хәб. – 1994. – 3 июнь.

8. Мөхәммәдиев Р. Мадам Анетт...: [язучы Рудольф Нуриев каберендә булган] // Сөембикә. – 1996. – № 12. – Б. 30–33.

9. Мөхәммәдиев Р. Мин бөркет булыр идем!: [язучыга 50 яшь] / әңгәмәдәш С.Гаффарова // Ялкын. – 1998. – № 11–12. – Б.4–5.

10. Мөхәммәдиев Р. Утлы таба өстендә: Баштан кичкән фаҗига // Мәдәни җомга. –1996. – 6 сент.

11. Мөхәммәдиев Р. Халкымның зирәклегенә ышанам: [язучы б-н әңгәмә] / Әңгәмәне Фирдәвес Зариф алып барды // Мирас. – 1998. – № 12.– Б. 4–14.

**Иҗаты турында:**

1. Ак кәгазь хаксызлыктан саргая...: [язучы Ринат Мөхәммәдиевнең «Ак кәгазь нидән саргая...» романы (Казан утлары. – 2019.– № 5–6) тур.] // Мәдәни җомга. – 2020. – 10 гыйнвар (№ 1). – Б. 11.

2. Ахунов Г. Утлы таба өстендә...: [язучы Ринат Мөхәммәдиев] // Идел. – 1998. – № 12. – Б. 48–49.

3. Әхмәдуллин А. «Ак кыялар турында хыял» повесте: [Ринат Мөхәммәдиевнең бу повесте (1995 ел) Мәгариф министрлыгы раслаган әдәбият программасы буенча 9 сыйныфта өйрәнелә] // Мәгариф. – 1999. – № 1. – Б. 24–28.

4. Әхмәтова Ч. «Сират күпере»нең дүртенче теле: [танылган язучы Ринат Мөхәммәдиевнең «Сират күпере» романы рус телендә басылып чыкты] // Шәһри Казан. – 1997. – 21 март.

5. Әшрәфҗанов Х. Тамырыбыз – тарихта: [1970 нче һәм 1980–1990 нчы елларда иҗат ителгән.тарихи романнар хакында Р.Мөхәммәдиевнең «Сират күпере» һ.б.] // Казан утлары. – 1998. – № 2. – Б. 146 –160.

6. Баянов Ә. Сәнгатьне фәнгә бәйләп: [Ринат Мөхәммәдиевкә – 50 яшь] // Ватаным Татарстан. – 1998. – 9 дек.

7. Вәлиев Н. Ринат Мөхәммәдиев: [язучы тур.] // Әдәби Алабуга. – 2005. – Б. 268–274.

8. Галимуллин Ф. Кече Кирмәннең олы Ринаты: язучы Ринат Мөхәммәдиевкә 50 яшь // Казан утлары. – 1998. – № 12. – Б. 134–141.

9. Галиуллин Т. Кенәриләрне читлектән очырганда...: [Ринат Мөхәммәдиевкә 50 яшь] // Мәдәни җомга. – 1998. – 11 дек. – Б. 12.

10. Галиуллин Т. Сәфәр чыгар аты бар...: [танылган әдип Ринат Мөхәммәдиевкә 50 яшь] // Мирас. – 1998. – № 12. – Б. 61–67.

11. Гаффар Ә. Чабата илә читек // Шәһри Казан. – 2000. – 15 дек.

12. Гаффар Ә. Яшенне турылый белгән зат: [язучы Р.Мөхәммәдиев тур.] // Мәгърифәт. – 1998. – 12 дек.

13. Гобәев Р.  Кеше һәм табигать: [Ринат Мөхәммәдиевнең «Беренче умырзая» повестена багышланган дәрес-конференция]// Мәгариф. – 2000. – № 6. – Б.34–36.

14. Даутов Р. Ринат Мөхәммәдиев: [язучы тур.] // Балачак әдипләре: биобиблиографик белешмәлек. Беренче китап=Писатели нашего детства: биобиблиографический справочник. Первая книга. – 2002. – Б. 134–140.

15. Еники Ә. Без кабызган утлар: [Уфада «Тулпар» исеме б-н татар телендә әдәби журнал чыга башлау уңае б-н язучылар фикере] // Тулпар. – 1994. – № 1. – Б. 2–3.

16. Закирҗанов Ә. Чорлар аша...: [язучы Ринат Мөхәммәдиевкә 70 яшь] // Мәдәни җомга. – 2018. – 7 декабрь (№ 48). – Б. 16.

17. Закирҗанов Ә. Яшьлеккә, туган җиргә мәдхия: [Р. Мөхәммәдиевнең «Кайларда сез, авылдашлар...» китабы тур.] // Мәдәни җомга. – 2022. – 13 май (№ 18). – Б. 18.

18. 50 яшьтә егеткә дан килә: [язучы Ринат Мөхәммәдиевкә 50 яшь] // Шәһри Казан. – 1998. – 18 дек.

19. Кадыоглу Мухсин. Төркиядә «буран» уйнады:

[язучы Ринат Мөхәммәдиевнең «Күзачкысыз буран» романы төрек телендә дә басылды] // Мәдәни җомга. – 2018. – 20 апрель (№ 15). – Б. 11.

20. Кыямов Р. Авыл матур уйлыймы?: [Р.Мөхәммәдиевнең «Истәлек өчен Гыйлемханга» хикәясе буенча төшерелгән яңа нәфис фильм тур.] // Мәдәни җомга. – 1995. – 17 нояб. – Б. 20.

21. Мансурова З. «Кеше барыбер кошлар нәселеннән...»: [Р.Мөхәммәдиевнең «Кош булып очар идем...» романы буенча дәрес-конференция]// Башкортостан укытучысы. – 2016. – № 12. – Б. 77–81.

22. Мифтахова С. Дәрес-презентация: [Р.Мөхәммәдиевнең «Сират күпере» романы буенча. Туган тел һәм әдәбиятны укыту. Лениногорск р-ны Ормышлы мәктәбе мисалында] // Мәгариф. – 1996. – № 3. – Б. 15–16.

23. Мостафин Р. Ничек яшисең, язучы? яки «Түгәрәк өстәл» янында әңгәмә: [катнаштылар: Ринат Мөхәммәдиев, Харис Әшрәфҗанов, Мөдәррис Вәлиев, Рафаэль Мостафин, Флүс Латыйфи, Мөдәррис Әгъләмов, Нәҗибә Сафина] / сөйләшүне Сәйдә Зыя язып алды // Татарстан. – 1994. – № 3–4. – Б. 55–61.

24. Роман турында сөйләшү: [Язучылар берлегендә язучы Ринат Мөхәммәдиевнең «Казан утлары» журналында дөнья күргән «Ак кәгазь нидән саргая» дип аталган романы тур. зур сөйләшү булды] // Мәдәни җомга. – 2019. – 11 октябрь (№ 40). – Б. 4.

25. Садә Г. Тәрәзә йөзлегенә песнәктәй кунган нурлы сүз: [Язучы һәм тәнкыйтьче, җәмәгать эшлеклесе Ринат Мөхәммәдиевкә 50 яшь] // Шәһри Казан. – 1998. – 4 дек.

26. Татар язучысын зурлыйлар: [Ринат Мөхәммәдиев Төркиянең әдәбият, сәнгать өлкәсендәге мәртәбәле премиясенә лаек булды] // Шәһри Казан. – 1995. – 1 апр.

27. Татарстан язучылары белән очрашу: [14 сентябрьдә Башкортстан Президенты М.Рәхимов Р.Мөхәммәдиевне,

Р.Харисны һәм Р.Мостафинны кабул итте] // Кызыл таң (Уфа). – 1994. – 16 сент.
28. Хайруллина Л.Р. Р.Мөхәммәдиевнең «Күзачкысыз буран» романында төрек сүзләренең роле һәм урыны // Итоговая научно-образовательная конференция студентов Казанского федерального университета 2017 года: сб. статей: в 6 т. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2017. – Т. 4: Институт психологии и образования. Институт филологии и межкультурной коммуникации им. Льва Толстого. – С. 387–389.
29. Хуҗиәхмәт Ф. Мин язучы түгел...: [язучы Ринат Мөхәммәдиев тур.] // Ватаным Татарстан. – 2004. – 23 июнь.
30. Шәрипова Т. «Сират күпере» русча сөйли: [язучы Р.Мөхәммәдиевнең «Сират күпере» романының русча тәрҗемәсе чыкты[ // Ватаным Татарстан. – 1997. – 14 март.
31. Шәфигуллина Р. XX гасыр татар әдәбиятында йорт-нигез образы һәм милли эстетика, метаморфозалар: [Г.Исхакыйның «Сөннәтче бабай», Ф.Шәфигуллинның «Өй салуның ние бар?», Р.Мөхәммәдиевнең «Истәлек өчен – Гыйлемханга» әсәрләре буенча] // Тюркологические исследования. – 2012. – № 4. – Б. 50 –59.

## КЕШЕ ҺӘМ ТАБИГАТЬ

*(«Беренче умырзая» повестен тәкъдим итү кичәсе)*

**1 алып баручы.** *(Ринат Мөхәммәдиевнең тормышы һәм иҗат эшчәнлеге белән таныштыра).*

Ринат Сафа улы Мөхәммәдиев 1948 елның 10 декабрендә Татарстанның Мамадыш районы Кече Кирмән авылында туган. 1966 елда – Түбән Ушмы урта мәктәбен, 1971 елда Казан Дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый...

**2 алып баручы.** Бүгенге кичәдә Ринат Мөхәммәдиевнең «Беренче умырзая» әсәрендә сурәтләнгән авыл тормышы, узган гасырның алтмышынчы, җитмешенче, сиксәненче еллары авылының социаль йөзен үзгәртүдә яшьләрнең өлеше турында сөйләшербез.

Язучының күпчелек әсәрләре туган ягына багышланган. Туган җир, туган туфрак... Бөек шагыйребез Габдулла Тукай – үзенең Кырлаен, Такташ Сыркыдысын мактаса, Ринат Мөхәммәдиев Кече Кирмәненә дан җырлый.

Ни әйтсәң дә, ул шушы авылда туып үскән бит, аның шифалы һавасын сулаган, олы тормышка юл алган.

**1 а.б.** Мин бу әсәрне бер утыруда укып чыктым. Повесть бик җиңел укыла. Әсәр үзәгендә – Рәхимҗан образы. Барлык вакыйгаларга да аның тарафыннан бәя бирелә. Ул кечкенәдән үк бабасына тартыла. Бабасы исә Рәхимҗанга, җае чыккан саен, авылның үткәне турында сөйли. Исемен дә аңа бабасы кушкан. Рәхимҗан, ягъни рәхимле җан. Исеме җисеменә туры килеп тора. Ул – туган авылының патриоты. Дөрес, ул да башта, иптәшләренә ияреп, шәһәргә китә. Авиация институтында укый башлый. Шәһәрдә чагында авылын, атлар кешнәвен сагына. Бабасы вафат булганнан соң, Рәхимҗан яңадан авылына кайта, бабасы урынына атлар карый башлый. Мондый сәер хәлдән соң яратып йөргән кызы Зәйнәп егеттән читләшә...

Флоттан кайткач, Рәхимҗан яңадан атлары янына ашыга. Читтән торып укып, институт тәмамлый. Әсәр ахырында без аның хөрмәтле җитәкче булып җитешүен күрәбез.

**2 а.б.** Рәхимҗан – авылның яшәеш шартларын үзгәртү, яңарту, яхшырту өчен көрәшә торган шәхес. Ул – саф күңелле, сабыр, үзендә җаваплылык хисе тоеп эш итүче заман герое. Кыюсыз, юаш булып күренгән егет безнең күз алдыбызда чыныгу үтә... Фаягөл белән алар ике малай үстерәләр. Фаягөл дә авыл хезмәтеннән курыкмый, шәһәрдән кайтып, сыер савучы булып эшли.

**1 а.б.** Төхфәт карт – авылның җанлы тарихы. Ул – бүгенгене үткән заман белән бәйләүче буын вәкиле. Аңа Рәхимҗан гына түгел, бөтен авыл малайлары тартыла. Аларны беренче тапкыр атка атландыручы да, ат сугару кебек җаваплы эшне ышанып тапшыручы да – Төхфәт бабай.

Нурлы Алан чишмәләре, инеш һәм елгаларның исеме каян килеп чыккан, теге яки бу тауны, юлларны нигә шулай атаганнар – Төхфәт карт һәммәсен мавыктыргыч вакыйгаистәлекләр аша күз алдына китереп бастыра. Авылдагы һәр агач һәм ерганакның да үзенә күрә үткәне, гыйбрәтле бер тарихы бар икән, ләбаса.

Чишмәләр тарихын да ул җиткерә Рәхимҗанга. Гаять дәрәҗәдә кешелекле, миһербанлы... Төхфәт карт, авыр хәлдә ятса да, авылдашы Гыймай белән судлашып йөрмәскә куша. Балалары жәл, ди. Ул инде үзенең үләсен белә, «Зиратның түбән башына күмәрсез. Су буеннан чишмә тавышы, атларның су эчкәндә пошкыруы ишетелеп торыр», – ди ул. Әйе, Төхфәт карт юкка яшәмәгән. Аның юлын дәвам итүче оныгы Рәхимҗан бар, ә Рәхимҗанның ике улы үсеп килә.

**2 а.б.** Төхфәт картның оныгына әйткән сүзләре – безгә дә, киләчәк буын яшьләренә дә эндәшү ул. «Кем булсаң да, бер нәрсәне онытма – без авыл кешесе. Шушы җирдән чыккан, шушында туган. Шушы кырларда үскән икмәкне ашап,

тау битеннән бәреп чыккан чишмә суларын эчеп үскән. Табигать безгә, үз балалары итеп, шундый уңдырышлы җир, туфрак биргән. Ниндиен телисең – шунысын эчегез, дигәндәй, берсеннән-берсе тәмлерәк сулы чишмәләр биргән.

Нурлы Алан егетләре һәрчак таза булып үссен, Нурлы Алан кызларының йөзеннән бер вакытта да алсулык китмәсен дип, бик күп чишмә агып тора. Берсенең суы икенчесеннән тәмлерәк. Күңелең кайсын тели, шунысын эч, дигән табигать. Кайда бар бездәге чишмәләр... Бер авылга йөзәү, исәпсез-хисапсыз ич алар. Һәркайсының үз тәме бар».

*(С.Хәким сүзләренә, Ә.Фәттах көенә язылган «Бер тауда ун чишмә» җыры фонында сөйләнә)*

**1 а. б.** Дүрт егет һәм кызның ял көнне урманга, Җәке каенлыгына беренче умырзаяларны җыярга барулары тирән мәгънәгә ия. Әсәрнең исеменә бәйле бу күренешне автор җанлы һәм ышанычлы итеп сурәтли:

«Гел уйламаганда Зәйнәпнең инеш челтерәвен хәтерләткән ягымлы тавышы ишетелде:

– Умырзая таптым, умырзая...

Бер-бер артлы Зәйнәп янына йөгерешеп килделәр.

– Берәү, икәү, өчәү, дүртәү – күрегез, күр, дүрт умырзая – дип сокланды Фаягөл. – Әйдәгез, һәркайсыбыз күңеленнән генә үзенең иң зур теләген әйтсен... Аннан соң гына берәр чәчәк өзәргә... Унҗиденче язларының беренче умырзаясына дүрт кул үрелде».

Фаягөлнең әйтелгән сүзләре дә тирән мәгънәгә ия.

– Безнең әби әйтә: язның беренче умырзаясын өзгәндә күңелдә булган уй чынга аша, ди. Ләкин бер шарт бар – ул сер булып калырга тиеш. Әсәрдә сурәтләнгән вакыйгалар аның сүзләренең дөреслеккә чыгуын күрсәтәләр.

**2 а.б.** «Беренче умырзая» әсәрендә авылның киләчәге турында кайгыртучы кешеләрнең берсе – колхоз рәисе

Мирзанур. Ул авыл халкы белән җылы мөгаләмәдә. Акыллы, белемле, тирән фикер йөртә белүче җитәкче сыйфатында бирелгән.

Рәхимҗанның якын дусты – шәһәргә ашкынучы Фаязның әсәр ахырында авылга бөтенләйгә кайтып төшүе җанлы картиналарда сурәтләнә.

Татар халкының бәйрәмнәре, гореф-гадәтләре, йолалары, һөнәрчелеге һәм җырлы-биюле уеннары да әсәрдә киң яктыртыла.

**1 а.б.** Ринат Мөхәммәдиев үзенең күпчелек әсәрләрендә ономастика мәгълүматлары белән оста эш итә белүен күрсәтте. Язучының «Беренче умырзаая» әсәрендә дә ономастикага караган материал – кеше исемнәре, гидронимнар, топонимнар, йолдыз атамалары һ.б. оста күрсәтелә. Элек-электән географик объектларга исемне халык аларның күзгә бәрелеп торган физик үзенчәлекләреннән чыгып биргән. Автор моны бик оста тотып алган һәм әсәрендә кулланган. Әсәрдәге атамаларны язучы үзе уйлап чыгармаган, аларны тормышның үзеннән алган. Хәзер менә шуларның кайберләренә тукталып китәрбез.

**2 а.б.** Авыл башындагы Нурлы Аланда чишмәлек бар – шуны Бакырчы чишмәсе диләр. Күбекләнеп, сары ком бөртекләрен berөзлексез биетеп дистәләгән нәни фонтанчыклар булып бәрә аның суы. Ләкин моны якыннан, чишмәнең янына килеп караганда гына күрергә мөмкин. Югарыдан, тау башыннан исә, ул әкиятләрдә генә очрый торган тылсымлы көзгене хәтерләтә...

Шуның тирәсендә үскән бөтнек башка беркайда да юктыр. Сабагының биек һәм куе булуы, яфракларының эрелеге һәм калынлыгы белән хәйран калдыра ул. Ә исе... Аны Бакырчы чишмәсе тугайлыгында булган, шундагы һаваны күкрәк тутырып сулаган кеше генә аңлый алыр. Бөтнек чәчәк аткан мәлдә су буеннан авылга таба җил дә исеп куйса, бөтен авылга шифалы хушбуй бөркелә. Урамнарны тутырып, ачык

тәрәзәләрдән өйгә кереп, күңелне, җанны иркәли аның исе.

**1 а.б.** Бакырчы чишмәсен бик борынгы диләр. Күп гасырлар элек монда килеп урнашкан ерак бабайлар, ул урында бакыр чыгарып, комган, самавыр кебек тормыш кирәк-яраклары, савыт-саба ясаган. Нурлы Алан бакырчылары ясаган комганнар бик ерак җирләрдә мәгълүм булган. Зур ярминкәләрдә шикәр-тоз кебек кирәк-яракка алмаштырып кайтканнар аларны. Шуңар Нурлы Аланлыларның комган осталары дигән даны таралган. Хәзерге чишмә урынында бакырчы алачыгы һәм тирән баз булган. Җир астыннан су чыга башлагач, бакырчылар башка урын эзләп киткән. Улларына, оныкларына әнә шундый шигъри матурлыкка ия чишмә калдырган Нурлы Аланның бакыр осталары...

Бу чишмә турында язучы, шагыйрь Рафаил Газизов болай ди:

Бакыр эзләгәннәр,
Базлар казып,
Кәйлә астыннан чишмә аваз салган.
Бабайларның гомере тарихларда
Бакырчылар булып чыңлап калган.

*(Әсәрдә телгә алынган яки тәфсилләп сөйләнгән башка чишмәләр турында да укучыларның чыгышын оештырырга мөмкин).*

**2 а. б.** Көннәрнең берендә «Нурлы Аланга мелиораторлар килгән», – дигән хәбәр таралды.

Мелиораторлар киләсе, колхозда зур мәйданда сугарулы җирләр буласы, дигән сүз күптән йөри иде инде. Арыш-бодай каерылып уңачак, күпьеллык үләннәр дүрт-биш тапкыр чабылачак, имеш. Авыл янында гына йөзеп тә чыга алмаслык зур диңгез хасил булачак, дип, шаккатып, исләре китеп сөйли иде Нурлы Аланлылар. Олысы-кечесе туган авылларында гөлбакча ясарга тиешле шул мелиораторларның килүен көтеп яшәде. «Диңгез ясаучылар» эшкә кереште...

**1 а.б.** «...Инешнең аргы ягында, элек чишмә булган ту-

рыда, ике бульдозер һаман да җир актара. Берсе артыннан икенчесе чиратлашып йөри-йөри каезлый иде алар чишмәле тау битен. Чишмә, бульдозер үткән саен, балчык һәм ташлар астында күмелеп кала. Ләкин озакка түгел, икенче бульдозер килеп җитәргә өлгерми, ком һәм балчык арасыннан фонтан булып яңадан бәреп чыга чишмә. Тагын, тагын. Шул рәвешле, берөзлексез үкереп эшләп торган зур-зур ике бульдозер белән тарткалаша иде Карт тирәк чишмәсе. Куеныннан алынган кызыл балчык инде тау кадәрле өелгән булуга карамастан, һаман бирешми, бирешергә теләми иде тирәксез калган Карт тирәк чишмәсе».

**1 а.б.** Рәхимҗанның, Дада абзыйның һәм колхоз рәисе Мирзанур абыйның катнашлыгында гына чишмәләр, тугайлар саклап калына. Ул елларда мондый күренешләр һәр авылда диярлек булып торды. Табигатькә күпме зыян ясалды, җиренә җиткерелеп уйланмаган эшләр башкарылды, күпме халык байлыгы җилгә очты.

Табигатьне, кош-кортларны, хайваннарны-җәнлекләрне саклау проблемасы язучы Ринат Мөхәммәдиевнең башка әсәрләрендә дә күтәрелә. Аның әсәрләрен укыганда, без туган ягыбызга икенче төрле күзлектән карыйбыз: елга буйлары, таллар, чишмәләр, урман-болыннар, күлләр, инешләр искә төшә. Язучы өчен туган як төшенчәсе урман, болын-кырлар белән генә чикләнми, бу төшенчәгә халыкның героик тарихы да, татар халкының буыннан-буынга күчеп килгән гореф-гадәтләре дә, матур киләчәге дә керә.

Бүген без язучы Ринат Мөхәммәдиевнең «Беренче умырзая» әсәрендә күтәрелгән мәсьәләләр, аларның чишелеше, Нурлы Аланның чишмәләре һәм кешеләре турында сөйләштек.

**2 а.б.** Хөрмәтле китап укучылар, үзебезнең авылдагы чишмә, кое, инеш, күлләрне кадерләп саклыйк, атамала-

рын онытмыйк. Туган авылыбыз тарихын өйрәник.

*(Г.Зәйнәшева сүзләренә, С.Садыйкова көенә язылган «Үз илемдә» дигән җыр яңгырый)*

*(Кичә тәмам).*

**Әдәбият исемлеге:**

1. Гобәев Р. Кеше һәм табигать: [«Беренче умырзая» повестена багышланган дәрес-конференция: (Ринат Мөхәммәдиев повесте)] // Мәгариф. – 2000. – № 6. – Б. 34–36.

2. Даутов Р. Ринат Мөхәммәдиев: [язучы тур.] // Балачак әдипләре: Биобиблиографик белешмәлек. Беренче китап=Писатели нашего детства: Биобиблиографический справочник. Первая книга. – 2002. – Б. 134–140.

3. Мөхәммәдиев Р. Беренче умырзая //Юлда булу хәерле: хикәяләр, повестьлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. – Б. 491 – 598.

**РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВНЕҢ
«СИРАТ КҮПЕРЕ»
КИТАБЫ БУЕНЧА ФИКЕР АЛЫШУ**

*Залга Ринат Мөхәммәдиевнең «Сират күпере» китабы, авторның портреты, кыскача биографик белешмә, Мирсәет Солтангалиев портреты, аның турында яңа китаплар, истәлекләр язылган газета-журналлар, Мулланур Вахитов, Гаяз Исхакый, Йосыф Акчура, Садри Максуди кебек милләтпәрвәрләрнең фоторәсемнәре, әсәрләре куелган.*




Хөрмәтле җәмәгать, соңгы вакытларда «халыкка кире кайтарылган исемнәр» дигән тәгъбирне еш ишетергә туры килә. Нәрсәне аңлата бу сүзләр?

Безнең элеккеге Советлар Союзында дәүләт башында бик озак еллар Сталин торган. Ул чор гаять авыр һәм катлаулы булган. Шул елларда күп кенә талантлы кешеләр бер гаепсезгә репрессиягә эләккән һәм халык дошманы дип игълан ителгән.

Бик озак еллар буе аларның исемнәрен дә әйтергә ярамаган. Менә хәзер шул кешеләрнең исемнәре халыкка кире кайта башлады. Күп тикшеренүләрдән соң, аларның гаепсезгә корбан булганлыгы, аяныч язмышлары ачыкланды.

Халыкка кире кайткан иҗатчы шәхесләребездән Ибраһим Сәлахов, Хәсән Туфан, Галимҗан Ибраһимов, Шамил Усманов, Кәрим Тинчурин, Фәтхи Бурнашларның исемнәрен атарга була.

Бүгенге фикер алышу бик соңлап булса да халыкка яңадан кайткан шәхескә, милләт өчен, аның азатлыгы өчен

көрәшкән каһарманнарыбызның берсе булган Мирсәет Солтангалиевкә багышлана. Сез барыгыз да беләсез, аңа багышлап, Ринат Мөхәммәдиев «Сират күпере» дигән әсәр язды. Бүген менә без сезнең белән тарихыбызның җаваплы бер чорын сурәтләгән әлеге әсәрне тәкъдир итәрбез.

Үз илебездә күп еллар буена М.Солтангалиевнең исемен телгә алырга ярамаса да, Франция, Англия, АКШ, Япония, Төркия һәм Алжирда аның эшчәнлеге, тормышы белән күренекле кешеләрнең кызыксынуын, аңа багышлап әсәрләр басылуын, үзенең «Сират күпере»н язгач, Америкадан чакыру алуын әйтә Ринат Мөхәммәдиев.

Инде әсәрнең үзенә килик тә, ил тарихын, татар тарихын барлап, М.Солтангалиев һәм башка каһарманнар юлларыннан узыйк.

Шушы урында Мирсәет Солтангалиевнең туган җире, гаиләсе турында белешмә бирелә. Алга таба китап укучылар белән түбәндәге план буенча әсәрнең эчтәлеге турында сөйләшү уздырыла:

– *«...Әти татарларга патшага каршы көрәшергә ярыймы?»;*

– *Казан белән беренче очрашу;*

– *Революция. Бер якта – милләт, икенче якта – партия;*

– *Татар егете М.Солтангалиев – дәүләт эшлеклесе;*

– *М.Солтангалиев идеяләренә һәм эшчәнлегенә күпчелек Шәрык илләре югары бәя бирә. Туран республикасы идеясе;*

– *Татарның батыр улы «сират күперен» сайлый;*

– *М.Солтангалиев һәм аның гаиләсенең юк ителүе – төрки халыкларның милли фаҗигасе.*

Без сезнең белән фаҗигале язмышлар эзеннән йөреп кайттык. Күреп торам: йөзләрегез җитди, дулкынланасыз. Әсәрне укып чыгуга, беркем дә тыныч кына утыра алмас, каядыр барасыгыз, бу фаҗигаләр булмасын өчен нәрсәдер

эшлисегез килер, шулай ук сездә соклану һәм горурлану хисләре дә кузгалыр.

М.Солтангалиев «татарларга гына өстенлек булсын» дип йөрми бит. Ул «татарларның да үз урыны булсын» дип тырыша. Әсәрдә бу хакта ачык әйтелгән. Ул үзе Зәки Вәлиди, Ильяс Алкин кебекләрне «милләт өчен генә» дип йөреп, ялгыш юлга керүдән һәрвакыт үгетләп килә, бик хәтәр сөйләшүләрдә катнаша.

Ничек уйлыйсыз, татарлар дәүләт белән идарә итәрлек милләт микән?

Әлбәттә, идарә итәрлек безнең халык. Әнә Мирсәет Солтангалиев һәм Мулланур Вахитов Мәскәүдә Ленин, Сталин янында әһәмиятле урыннарда эшләгәннәр бит! Аларның эшчәнлеген Шәрык илләре дә таный.

Солтангалиевнең үлемен милләтнең фаҗигасе дип буламы?

Әгәр Солтангалиевнең идеяләре тормышка ашып, ул заманда мөстәкыйль республика төзелгән булса, без инде алга киткән илдә яшәр идек. Татар теле дә бүгенгечә мескен хәлдә түгел, бәлки чәчәк аткан булыр иде.

Әсәр ни өчен «Сират күпере» дип атала? (М. Солтангалиевнең көрәш юлын, язмышын сират күперен кичүгә тиң дип бәяләргә була).

Мирсәет Солтангалив шәхесе белән чит илләрнең күренекле кешеләре кызыксынуына бер дә гаҗәпләнәсе юк икән. Аның идеяләре, шәхесе күп яклары белән үзенә тартып тора. Ул олы җанлы зат булган. Шунысы бар: аның идеяләре бүгенге дөньяның хәл ителмәгән мәсьәләләре белән аваздаш.

Россиянең киләчәге турында ул әйткән фикерләрнең хаклыгын тормыш инде раслаган. Һәр милләт үзбилгеләнү хокукына ия булганда гына ныклы нигезле дәүләт төзергә мөмкин икән.

М.Солтангалиевкә һәм аның эшчәнлегенә татарларның

үз зыялылары да игътибар юнәлттеләр. Индус Таһиров, Булат Солтанбеков, Дамир Шәрәфетдинов, Рафаил Хәкимов һ.б. бу шәхесне өйрәнеп, мәкаләләр яздылар. Ә инде Ринат Мөхәммәдиевнең «Сират күпере» әсәрен М.Солтангалиевкә әдәби һәйкәл куюдип бәяләргә кирәк!

**Әдәбият исемлеге:**

1. Мөхәммәдиев Р. Сират күпере: тарихи роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. – 541 б.

2. Мифтахова С. Дәрес-презентация: [Р.Мөхәммәдиевнең «Сират күпере» буенча. Туган тел һәм әдәбиятны укыту. Лениногорск р-ны Ормышлы мәктәбе мисалында] // Мәгариф. – 1996. – № 3. – Б. 15–16.

# РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВНЕҢ «АК КЫЯЛАР ТУРЫНДА ХЫЯЛ» ПОВЕСТЕ ТУРЫНДА ФИКЕР АЛЫШУ

**Фикер алышу өчен темалар:**

I. Ринат Мөхәммәдиев – тәнкыйтьче һәм язучы.

II. «Ак кыялар турында хыял» повестеның төп проблемасы.

1. Әсәрнең үзенчәлеге.
2. Янәшә сурәтләнгән язмышлар:

а) ак кыялар турында хыялланучы Микәй;

б) хәмер аркасында таркалган гаилә.

3. Төп фикерне бирү өчен кулланылган чаралар.

III. Р. Мөхәммәдиев әсәрләренең әһәмияте.

Әүвәл әхлак бозыла, икенче дин бетә,<br>
өченчедән, ул халык үзе бетә.<br>
*Гаяз Исхакый*

Р. Мөхәммәдиев әдәбият мәйданына тәнкыйтьче буларак килеп керә. Мәсьәләләрне тирәннән, җитди итеп күтәреп, үз фикерен кешеләр колак салырлык итеп әйтүе аны чын тәнкыйтьче итеп таныта. Ул бер үк вакытта шигъриятне дә, чәчмә әсәрләрне дә өйрәнә. Иҗат индивидуальлеге булмаган «шигырь ясаучылар» турында исә тәнкыйтьченең сүзе кискен. Ул «күңелдән, йөрәктән кат-кат кичерми, тема белән рухланып йокысыз төннәр үткәрми» генә язылган шигырьләрнең шигъриятебез үсешенә зыян китерүен искәртә, әдәбиятыбызның югары дәрәҗәсен саклау турында кайгырта. Хәзерге көндә ул – күп хикәяләр, повесть һәм романнар авторы. «Көчәнми язуы, йөгерек каләме һәм телгә тоемы, заманча фикерләве белән «Ак кыялар турында хыял» повесте аеруча матур тәэсир калдыра», – ди тәнкыйтьче Ф. Миңнуллин.

«Ак кыялар турында хыял» әсәренең төп үзенчәлеге – аның үзәгендә кәҗә тора. Ләкин ул кешеләр язмышыннан аерым, үзбашка гына сурәтләнми. Кәҗә белән аерым кешеләр арасында янәшәлек бара, язмышларында охшашлык сизелә. Кешеләр тормышында тамыр җәйгән афәт табигать баласы язмышы ярдәмендә күзәтелә. Аның кешеләрне генә түгел, гөнаһсыз хайваннарны да түбәнлеккә өстерәве сурәтләнә. Бу афәт – эчкечелек, инде гомер-бакый тәрбия һәм әхлак учагы булган авылларыбызда да үзенең кара эшен җәелдергән бәла – авыру.

Вакыйгалар артык катлаулы түгел. Ләкин тышкы гадилек артында тирән мәгънә ята.

Ак кыялар иленнән тотып алып, авылга кайтарылган кәҗә бәтие Микәй кешеләр янында яшәвен өнәп бетерми. Ул үзенең туган якларын, туганнарын еш исенә төшерә, шул якларга кире кайту өчен берничә мәртәбә юлга да чыга. Әмма ак кыялар турындагы бу олы хыялы берничек тә тормышка ашмый. Алай гына да түгел, яшәешен ямьләндереп торган хыял кырыс чынбарлыкка бәрелеп чәлпәрәмә килә. Үзен бик яраткан авыл малайлары Азат белән Миңлегаязлар аны авыл мохитен кабул итәргә, кешеләргә ышанырга өйрәтәләр. Адәм балаларына ышанган хайван алардан яман гадәтләргә дә тиз ияләнә: тәмәке тарта һәм чәйни башлый, аракы эчәргә өйрәнә, гомерен дә алкоголь чиреннән фаҗигале тәмамлый.

Авылга читтән тагын бер җан иясе килә. Монысы – Айсылу, күрше авылның чибәр һәм уңган кызы килен булып төшә. Басынкы табигатьле Миңлегали белән гаилә корып җибәрәләр. Ләкин бу гаилә шул ук аракы аркасында бик тиз таркала. Миңлегали, аракыга хирысланувы аркасында, алдынгы механизатордан капчык хисаплаучы әрәмтамакка әверелә. Автор болар турында бик аз яза, әмма Микәйнең шуңа охшаш язмышын тәфсилләү ярдәмендә, Миңлегалине онытырмый. Шуңа да тайгак юлга кереп баручы Микәйнең язмышы Миңлегалинең эчке халәтен дә ачып бирә сыман.

Хәмер әсәрнең башында ук килеп керә. Күңелгә шом салып, аракы тулы касәләр чыңлый. Кибеткә аракы кайтуга бар халык шунда ашыга. Шунда ук укучы читенсенеп кенә булса да, чиратта торучы Миңлегалине күрә. Автор боларны юкка гына җентекләп сурәтләми. Ул авылларга килүче афәт турында кисәтә. Авыл халкы, әкренләп, упкынга якынлаша.

Автор, төп фикерне бирү өчен, төрле чаралар куллана. Шуларның берсе – төсләр. Әсәрнең башыннан ахырына кадәр ак төс Микәйнең юлдашы булып бара. Без аның, лапас кыегына менеп, аклыкка соклануын күрәбез: «Бөтен әйләнә-тирә ап-ак юрган астында. Урамнар гел актан. Ак түбәләрдә ара-тирә ап-ак төтен чыгып тора. Ул төтен, ак багана булып, ак болытларга барып тоташа. Ак болытларның аръягында да аклык микән...»

Микәйне бүре авызыннан да ак кар коткарып кала: «Кибән янына сарган кар, ни хикмәттер, каты булып чыкты – аяклары батмады Микәйнең. Әллә ак төснең аны үз итүе булды – ак кар аны иңнәренә алды».

Ләкин табигать ак төсләрдән генә тормый, башка төрле төсләр дә күп. Шулар арасыннан яшел төс аклык белән янәшә куеп бирелә. Микәй сөйгәне Шомырткара белән озак кына бәхәсләшә. Аны ак кыялар иленә, аклык дөньясына китәргә өнди. Ләкин Шомырткара «яшел хәтфә сыман иңкүлекләр, урман-кырлар, челтерәп аккан шаян инешләрне» артыграк күрә. Шуннан соң ул яшел төсне үзенең гомерлек хыялы булган аклыкка тәңгәл итеп күрә башлый: «Ике ут арасында чарасыз калган Микәй уянып китте. Ишегалдында иртәнге ыгы-зыгы башланган. Өй каршындагы ак каеннарның бөдрә тармакларыннан мөлдерәп торган яшел нурлар коела. Микәй әле генә игътибар итте: җанына аеруча үз булган, аклыклары белән берөзлексез аның карашларын иркәләп торган каеннар дөньяга яшел нур чәчә икән бит. Ак төс һәм яшел төс – Микәй белән Шомырткара дигән сүз. Аларны бер-берсенә каршы куеп, Микәй ялгышкан икән ич...»

Ак төс ышаныч, хыял белән бергә бирелә. Микәй үзе яшәгән тормышның тискәре якларын ача барганы саен, кешеләргә аның ышанычы кимегәне саен ак төс тә сыегая бара. Микәй күңелендәге ак хыяллар да сүрәнләнә, аларга алмашка яшел төс килә.

Ак һәм яшел – безгә иң якын төсләр. Беренчесе сафлык, пакьлек төсе булса, икенчесе – яшәрү, яңару төсе.

Әкренләп, ак һәм яшел төсләргә алмашка соры төс килә. Соры төс – яшәүдә эчпошыргыч бертөрлелек, гамьсезлек, сүнү төсе. Хәтта әшәкелек төсе. Автор юкка гына бүрене «авыр гәүдәле» «соры бүре» дип сурәтләми. Соры төснең Микәй тормышына килеп керүенә шул ук хәмер гаепле. Микәй өчен хәзер бөтен дөнья көл төсенә керә: «...Әйе, эчүчелекнең соңы – соры, күңелсез, фаҗигале».

Р. Мөхәммәдиев төсләр ярдәмендә җитди фикер уздыра, чаң суга. Мәхлук хайванны һәлакәт юлына этәргән аракыны, шуңар табынган кешеләрне гаепли һәм шелтәли.

«Ак кыялар турында хыял» повесте эчкечелек кебек яман чирнең Айсылу белән Миңлегали бәхетен, мәхәббәтен җимерүе хакында. Бу тарихны көчәйтү өчен сурәтләнгән кәҗә тәкәсе язмышы автор керткән шартлы алым-образ аша әлеге фаҗигане бөтен тирәнлегендә күрсәтә. Заманыбызның авыр бер мәсьәләсен, кешелекне упкынга сөйрәүче эчкечелек чиренең начарлыгын күрсәтүе белән бу повесть әдәбиятта уңай бәяләнә.

Р. Мөхәммәдиев үзенең әсәрләрендә ниндидер начар гадәтләр, тәртипләр аркасында бәхетнең җимерелүе, чәлпәрәмә килүе, аерым очракларда чатнап, кителеп куюы турында яза. Укучыларны бозыклык юлыннан китмәскә өнди, начар гадәтләргә каршы көрәшергә кирәклеген искәртеп тора. Аның әсәрләре тәрбияви яктан көчле. Безнең фикеребезчә, Р. Мөхәммәдиев әсәрләре киләчәктә дә укучылар тарафыннан яратып укылыр. Аның

әсәрләрендә күтәрелгән проблемалар гына киләчәктә булмасын иде.

**Әдәбият исемлеге:**

1. Әхмәдуллин А. «Ак кыялар турында хыял» повесте: [Ринат Мөхәммәдиевнең бу повесте (1995 ел) Мәгариф министрлыгы раслаган әдәбият программасы буенча 9 сыйныфта өйрәнелә] // Мәгариф. – 1999. – № 1. – Б.24–28.

2. https://tatteacher.ucoz.net/d-bjattan-zer_inshalar.docx Яраткан язучым турында сөйләргә телим...

## ВИКТОРИНА ҮТКӘРҮ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Ринат Мөхәммәдиев кайчан һәм кайда туган?

*(1948 елның 10 декабрендә Татарстанның Мамадыш районы Кече Кирмән авылында)*

2. Аның беренче хикәяләр җыентыгы кайчан басылып чыга?

*(«Яңа елга күчтәнәч» исемле җыентык, 1979 елда басылып чыга)*

3. Кайсы елда нинди темага диссертация яклаган?

*(1979 елда «Татар әдәби тәнкыйтенең формалашу проблемалары» дигән темага)*

4. Ринат Мөхәммәдиев университет тәмамлагач хезмәт юлын кайда һәм кем булып башлый?

*(Казан телевидение студиясендә яшьләр-балалар тапшырулары мөхәррире)*

5. Ринат Мөхәммәдиевкә кайчан һәм нинди әсәре өчен Г. Тукай премиясе бирелә?

*(1993 елда «Сират күпере» романы өчен)*

6. Кайсы елларда Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе булып эшләгән?

*(1989 – 1999 елларда)*

7. Түбәндәге юллар әдипнең кайсы әсәреннән алынган?

*«Бабасы Рәхимҗанга, җәй туры килгән саен, авылның үткәне хакында сөйләргә тырыша. Нурлы Алан чишмәләре, инеш һәм коры елгаларның исеме каян килеп чыккан, теге яисә бу тауны, юлларны нигә шулай атаганнар – Төхфәт*

*карт һәммәсен мавыктыргыч вакыйга-истәлекләр аша күз алдына китереп бастыра иде. Авылдагы һәр агач һәм ерганакның да үзенә күрә үткәне, гыйбрәтле бер тарихы бар икән ләбаса!»*

*(«Беренче умырзая»повестеннан)*

8. Түбәндәге юллар кайсы әсәреннән?

*«Ә Микәй – текә кызыл ярдан әле генә тәгәрәп төшкән Микәй – кагынырга да онытып тик басып торуын белә. Мәңге шулай дәвам итәр кебек иде, хурлык һәм гарьлекнең чиге-чамасы юк. Бу кызганыч халәтеннән ул котыла алган булыр идеме икән?.. Әгәр шунда кызыл яр читеннән Шомырткараның нәфис маңгае, җыйнак мөгезләре күренмәгән булса...»*

*(«Ак кыялар турында хыял» повестеннан)*

9. Түбәндәге юллар кайсы повестеннан?

*«Шушы хәлдә торып калган сыңар тәрәзә йөзлеген һәм күкчәчәкләрне мондый түбәнлектән ул ничек коткара ала иде соң?.. Гыйлемхан йөзлекне җәһәт кенә иңбашына салды да, алпан-тилпән атлап, бакча түренә, дөрләп янган учакка таба китте. Ике олы хисне – туган нигезгә һәм Миңсылуга булган мәхәббәтен берьюлы мәңгеләштереп торырга тиешле тәрәзә йөзлеген ут телләре ялмап кына алды. Янды...Чарт-чорт килеп, дөрләп янды күкчәчәкләр. Утлы күмергә әверелгәч тә, бертын таралмый, уалмый торды әле алар. Ул чәчәкләрнең хәтта көлендә дә зәңгәрлек бар иде сыман...»*

*(«Истәлек өчен – Гыйлемханга» повестеннан)*

10. Ул ничәнче елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы?

*(1979 елдан)*

11. Ринат Мөхәммәдиев нинди повесте өчен М.Шолохов исемендәге Халыкара премиягә лаек була?

*(«Крушение» («Утлы таба өстендә») повесте өчен 2002 елда)*

12. Аның нинди китаплары рус теленә тәрҗемә ителгән?

*«Крушение» («Утлы таба өстендә»), «Львы и канарейки, и невинные забавы мафии» («Кенәри – читлек кошы»), «Мост над адом» («Сират күпере»), «На раскалённой сковороде» («Утлы таба өстендә»), «Свои люди» («Үз кешеләр») һ.б. Кыскасы, автор үзенең барлык әсәрләренең дә рус һәм дөнья халыклары телләренә тәрҗемә ителүен кайгырта*

13. Хәзерге көндәге эш урыны?

*(Халыкара Язучылар берлегенең рәис урынбасары, Мәскәүдә чыга торган «Татарский мир» («Татар дөньясы») дигән иҗтимагый-сәяси газетаның баш мөхәррире вазифаларын башкара).*

# ЭЧТӘЛЕК

Кереш сүз ........................................................................ 3
Әңгәмәләр үткәрү өчен якынча темалар......................... 13
Кеше һәм табигать («Беренче умырзая» повестен тәкъдим итү кичәсе) ........................................................ 20
Ринат Мөхәммәдиевнең «Сират күпере» китабы буенча фикер алышу....................................................... 27
Ринат Мөхәммәдиевнең «Ак кыялар турында хыял» повесте турында фикер алышу ........................................ 31
Викторина үткәрү өчен сораулар..................................... 36

Басарга кул куелды 28.06.2023. Форматы 60x84  1/16.
Тиражы 75 данә. Заказ № 479.
Татарстан Республикасы Милли китапханәсе,
«Милли китап» нәшрияты.
420015, Казан шәһәре, Пушкин ур., 86 йорт.

Подписано в печать 28.06.2023. Формат 60x84 1/16.
Тираж 75 экз.  Заказ № 479.
Национальная библиотека Республики Татарстан,
Издательство «Милли китап».
420015, г. Казань, ул. Пушкина, д. 86.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең
редакция-нәшрият бүлегендә басылды.
420015, Казан шәһәре, Пушкин ур., 86 йорт.